| СОВЕТ<br>ЕРЫКЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | с. Ерыкла | **КАРАР** |
| 01.07.2022 | | № 25 |

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү Тәртибен раслау турында» 25.09.2017 № 50 номерлы Зирекле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (08.04.2022 ел № 23 дагы үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2022 ел, № 90-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә,

**Зирекле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында ,25.09.2017 № 50 номерлы Зирекле авыл

җирлеге Советы карары белән  расланган Тәртипкә  3 пунктның г пунктчасын түбәндәге редакциядә биреп үзгәрешләр кертергә :

«г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда муниципаль вазыйфа биләүченең һәм аның хатынының (иренең) гомуми керемённән артып китсә һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында.».

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенец мәгълүмат стендларында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Зирекле авыл**
**җирлеге Башлыгы**
**Совет рәисе**

**В. А. Данилова**